ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 июнь, 2017 ел № 17/10

Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге 27/15 санлы Карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, 2002 елның 10 январендәге «Тирә-юнь мохитне саклау турында» 7-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсе, шәһәр Уставының 28, 41 маддәләре нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге 27/15 санлы Карары (Шәһәр Советының 2013 елның 19 декабрендәге 28/14 санлы Карары редакциясендә) белән расланган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турында нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 пунктка түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«шулай ук тирә-юнь мохитне саклау буенча чаралар һәм экологик экспертиза үткәрү.»;

2) 11 пунктның 1 пунктчасына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«тирә-юнь мохитне саклау һәм экологик экспертиза өлкәсендә законнар.»;

12 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 27-37 пунктчаларны өстәргә:

«27) җир асты байлыкларын файдалануга биргәндә, территориядә яшәгән халыкның социаль-экономик һәм экологик мәнфәгатьләрен яклауга бәйле мәсьәләләрен хәл итүдә катнашу;

28) гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзелешен алып барганда җир асты байлыкларыннан файдалануны һәм саклауны тикшереп тору;

29) башка административ-терриотриаль берәмлек билгеләгән хуҗалык яки башка эшчәнлекнең тирә-юнь мохиткә мөмкин булган йогынтасы очрагында, экологик экспертиза объектларына дәүләт экологик экспертизасы эксперт комиссияләре утырышларында күзәтчеләр сыйфатында катнашу өчен экспертлар җибәрү;

30) җәмәгать фикер алышулары, сорашулар, референдумнар, иҗтимагый экологик оешмаларның (берләшмәләрнең) һәм хәрәкәтләрнең гаризалары, экологик экспертиза объектлары турында мәгълүмат нәтиҗәләре нигезендә экологоик экспертиза мәсьәләре буенча үз вәкаләтләре чикләрендә карарлар кабул итү һәм гамәлгә ашыру;

31) халык арасында экологик экспертиза үткәрелергә тиеш күздә тотылган хуҗалык яки башка эшчәнлек турында җәмәгать фикер алышулары, сорашулар, референдумнар үткәрү;

32) халык таләбе буенча экологик экспертизалар үткәрү;

33) экологик экспертиза өлкәсендә башкарма комитетның федераль органнарына тиешле муниципаль берәмлек территориясендә күздә тотылган хуҗалык яки башка эшчәнлек турында хәбәр итү;

34) прокуратура, экологик экспертиза өлкәсендә башкарма комитетның федераль органнарына һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына дәүләт эколгик экспертизасының уңай бәяләмәсеннән башка экологик объектны гамәлгә ашыра башлау турында хәбәр итү;

35) җирле әһәмияттәге аеруча саклანучы табигать территорияләреннән файдалану һәм саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

36) үзагачның берәмлек күләме өчен түләү күләмен билгеләү буенча тәкъдимнәр хәзерләү;

37) урман хуҗалыгы регламентларын эшләү, шулай ук урманнарны үзләштерү проектларына муниципаль экспертиза үткәрү.»

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев